СӨЯ ГОМЕРНЕ, СӨЯ ХАЛЫКНЫ, СӨЯ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 8 июленнән бирле чыга. | №74 (7247) | 22 июнь, 1991 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

## Болында

**«1 Май колхозы».** Биредә 180 гектар мәйдандагы печәннең 100 гектары чабылды. Кырда Анатолий Аркадьевич Герасимов җитәкчелегендәге звено хезмәт куя.

МТЗ-80 тракторчылары Петр Петрович Назаров, Александр Васильевич Семенов КС-2,1 агрегаты белән үләннәрне чабуда аеруча өлгерлек күрсәтәләр. Алар көнлек нормаларын 150—170 процентка үтәп баралар.

Теземнәрне әйләндерүдә исә тракторчы Иван Петрович Варламовның да ГВК-6 агрегатында хезмәте зур.

Көннәр аяз торганда киптерелгән печәнне тизрәк өю өчен Владимир Ильич Короткин вакыт белән исәпләшми. Кибәнне тыгызлап торучылар Николай Егорович Варламов, Степан Константинович Ивановның да эшләренә телтеш тидерерлек түгел.

Шундый темпта эшләгәндә якын көннәрдә кырда печән чабылып һәм җыелып бетәчәк.

**Г. РИЗАТДИНОВА.**

## АРТЫМ ЯХШЫ

Ульянов исемендәге колхозның товарлыклы-сөтчелек фермасы хезмәтчәннәре ел башыннан уңышлы старт алдылар. Хәзер алар кабул итеп алган йөкләмәләрне һәм еллык планнарны арттырып үтәү өчен җиң сызганып эшлиләр.

Минҗиһан Галәветдинова, Әлфия Йосыпова, Әминә Кәлимуллина агымдагы елның биш аенда профилакторий группасындагы бозаулардан 500 грамм уртача тәүлеклек артым алдылар.

Хуҗалык буенча исә мөгезле эре терлекләрдән ел башыннан алынган уртача тәүлеклек артым 590 грамм тәшкил итә.

**А. ДАУТОВА.**

## Җиләк-җимеш питомнигында

Җиләк-җимеш питомнигында да бу көннәрдә эш киеренке. Хатын-кызлар Роза Алексеева, Полина Акмуллина, Галина Кадяшева, Раиса Осипова, Гөлсирә Абдуллина, Луиза һәм Сания Кадыйровалар карлыган, алмагач, чия үсентеләренең төпләрен йомшарталар.

Гомуми мәйданы 230 гектар булган бакчада тракторчылар Юрий Степанов, Алексей Кадяшев, Егор һәм Валерий Осиповлар культивацияләү үткәрделәр һәм рәт араларын эшкәрттеләр.

Хәзер, виктория җиләген үз вакытында җыеп алу өчен дә зур тырышлык куела. Аны җыю өчен Норлат, Яр Чаллы шәһәрләреннән, Чаллы Башы районыннан да киләләр.

Викториянең килограммы 5 сум 50 тиеннән сатыла.

**С. ФРОЛОВА,**
**кассир.**



**«Рассвет» совхозының икенче товарлыклы-сөтчелек фермасы сыер савучысы Әлфия Минсәлиховна Тимербикова турында гел җылы сүзләр генә әйтергә була. Ул бүгенге көндә Ринат Һадиевич Тимербулатов җитәкчелегендәге звенода эшли. Ә фермада хезмәт куюына бөтенләе белән 15 еллар чамасы вакыт узган. Шул дәвер эчендә сынатмады, җитәкчеләрнең ышанычын аклады ул.**

**Узган елны һәр сыердан уртача 4000килограмм сөт сауган иде. Быел да шул чиккә җитәргә омтыла.**

**Агымдагы елның биш аенда Әлфия Минсәлиховна бер сыерга уртача 1485 килограмм сөт сауды инде. Аның кабул итеп алган йөкләмәләрне һәм еллык планнарны үтәвенә шик юк.**

**Рәсемдә: сыер савучы Ә. М. Тимербекова.**

## Машина-трактор паркында

**«Восход» колхозы».** Урып-җыю чорына комбайннарны көйләп, ремонтлап бетерү өчен механизаторлар һәр минутны рациональ файдаланып эшлиләр.

Механизаторлардан Владимир Алексеев, Владимир Тиманкин, Евгений Демьянов, Валерий Яковлев, Николай Инякин, Василий Абрамов бүгенге көнгә 6 комбайнны яхшы сыйфатлы итеп әзерләп алгы сызыкка куйдылар инде.

**Н. АБРАМОВ,**
партоешма секретаре.

## Семинар-киңәшмә үтте

20 июньдә Ульянов исемендәге колхоз базасында Октябрь, Аксубай, Чирмешән, Яңа Чишмә районнары вәкилләре катнашында республика зона семинары үтте.

Ул отчетлылык, базар мөнәсәбәтенә күчкәндә хезмәткә түләү һәм финанслау мәсьәләләренә багышланган иде. Аның теоретик өлешендә авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек Министрлыгының план бүлеге начальнигы М. К. Кашапов, Министрлыкның баш бухгалтеры П. М. Кальцев һәм финанслау бүлеге начальнигы Т. З. Җамалиев, экономик мөнәсәбәтләр һәм бәяләр бүлеге баш экономисты Ш. Б. Әбделганиев, министрлыкның баш экономисты К. Ш. Шиһапов әлеге теманы һәрьяклап яктырттылар, хисап, финанслау, хезмәтне нормалаштыру һәм түләү өлкәсендәге яңалыклар белән таныштырдылар. Шунда ук Ульянов исемендәге колхоз рәисе В. М. Даутовның хуҗалыкның финанс-экономик эшчәнлеге турында чыгышы да тыңланды. Бу семинарның практик өлешендә колхозда хезмәтне яңача оештыру белән танышуга беркадәр аңлатма да иде. Практик өлештә катнашучылар Х. Даутовның фермер хуҗалыгын, Г. Даутовның карабодай чистарту, И. Мостафинның он тарттыру буенча кече предприятиеләре эшчәнлеген зур кызыксыну белән карадылар.

## Хаҗга бару

**Хаҗга барасы килгән кеше мөселманнарның дини нәзарәтенә мөрәҗәгать итәргә тиеш. Анда гаризалар тикшерелә, исемлекләр төзелә һәм бару тәртибе билгеләнә.**

**СССР Эчке эшләр министрлыгы белән килешеп документлар тутырыла. Хаҗга барырга теләгән кешеләргә нинди дә булса чикләүләр юк. Бөтенесе сәяхәтне валюта белән тәэмин итүгә барып терәлә. Валютаны гадәттә мөселманнарның диния нәзарәтләре бирә. Шулай ук дин тотучыларның үз акчаларына хаҗга бару да мөмкин. Хәзерге вакытта предприятиеләр, кооперативлар аерым кешеләргә дә, мөселманнарның зур бер төркеменә дә финанслар бирү белән шөгыльләнә.**

**Самолет билетена, кунакханәдә торган өчен, транспорт өчен түләүләрдән тыш хаҗ кылучы Согуд Гарәбстанына кергәндә 210 доллар күләмендә пошлина түли.**

**Былтыр бездән барган дәрвишләргә транспорт, кунакханә, ашау хакын Согуд Гарәбстаны хөкүмәте түләде.**

**Узган елга кадәр хаҗга баручы мөселманнар саны елга 30 кешедән артмый иде. 1990 елда алар 1528 кеше булды. Шуларның 8е Мәккәдәге этеш-төртеш вакытында һәлак булды. Шул чагында ук хаҗга баручыларга валюта икеләтә норма белән, 600 доллар күләмендә сатылган иде. Әмма быел алыштырыла торган валюта суммасы 200 доллардан артмаячак.**



**«Мамык» совхозының товарлыклы - дуңгызчылык фермасында Наталья Дмитриевна Илларионова озак еллар хезмәт куя. Бүгенге көндә ул 2 айга кадәр һәм аннан да зуррак булган дуңгызлар карый. Агымдагы елның 5 аенда алардан 359 ар грамм уртача тәүлеклек үсеш алуга иреште.**

**Хуҗалыкның товарлыклы-сөтчелек фермасында бозау караучы булып эшләүче Елена Васильевна Осипова да сынатмый. Кышкы чорда ул профилакторий группасындагы бозаулардан 598әр грамм уртача тәүлеклек артым алган иде. Җәйге чорда исә Елена Васильевна ире Аркадийга булышу өчен совхоз умарталыгына эшкә китә.**

**Рәсемдә сез дуңгыз караучы Наталья Дмитриевна Илларионова белән бозау караучы Елена Васильевна Осипованы күрәсез.**

**Н. Азизов фотосы.**

## 1991 ел 12 июньдә булган сайлау йомгаклары турында шәһәр сайлау комиссиясе БЕЛДЕРҮЕ

Татарстан ССРның Октябрь районы халык депутатларының Норлат шәһәр Советына халык депутатлары сайлау буенча участок сайлау комиссияләре беркетмәләрен карап, шәһәр сайлау комиссиясе түбәндәгеләрне хәбәр итә: Норлат шәһәр Советына халык депутатларын сайлау буенча сайлау исемлегенә 729 сайлаучы кертелгән иде. Сайлауларда аларның 439ы катнашты.

Тавышлар түбәндәге тәртиптә бүленде.

11 нче округ буенча 391 сайлаучы теркәлгән иде. Тавыш бирүдә 213 сайлаучы катнашты. Депутатлыкка кандидат Нина Алексеевна Андрееваны яклап 184, каршы 29 сайлаучы тавыш бирде. Дөрес түгел дип табылган бюллетеньнәр булмады.

21 нче сайлау округы буенча 338 сайлаучы теркәлгән иде. Тавыш бирүдә 226 сайлаучы катнашты. Депутатлыкка кандидат Фәрит Ислам улы Гайнуллинны яклап 185, каршы 41 сайлаучы тавыш бирде. Дөрес түгел дип табылган бюллетеньнәр булмады.

Татарстан ССРның «Татарстан ССР халык депутатларының җирле Советларына халык депутатлары сайлаулар турында» Законның 51 статьясы нигезендә халык депутатларының Норлат шәһәр Советына халык депутатлары итеп сайландылар:

11 нче сайлау округы буенча 1958 елда туган, Норлат шәһәрендә яшәүче, азык комбинатының крендель-кондитер цехы эшчесе НИНА АЛЕКСЕЕВНА АНДРЕЕВА;

21 нче сайлау округы буенча 1957 елда туган, Норлат шәһәрендә яшәүче, район Советы башкарма комитетының МПП-сы (күптармаклы производство предприятиесе) начальнигы Фәрит ИСЛАМ улы ГАЙНУЛЛИН.

**Шәһәр сайлау комиссиясе.**

## Район газетасына 60 яшь

### Тарихи җиңү көнендә

Верховный баш командующий Советлар Союзэ маршалы иптэш Сталинның 1 нче май приказы басылган газетаны алу белән колхозда, бригадаларда һәм аерым колхозчылар арасында приказны дулкынлану белән өйрәнү башланды.

Колхозчылар бу тарихи документка җавап итеп, язгы чәчүне иң кыска срокта, яхшы сыйфатлы итеп үтәргә сүз бирделәр. Сүз эштән аерылмады, һәркем тагын да яхшырак эшли башлады. Л. Осипов, Л. Ефимов иптәшләр бәйрәм көннәрендә чәчү нормасын 117 процент итеп үтәделәр. А. Левакова, Н. Федорова иптәшләр үзләренең сыерларын җиге 3 гектар мәйданда яхшы сыйфатлы сөрү үткәрделәр. Тырышлык бушка китмәде. Колхоз башаклы һәм бөртекле культуралар чәчү планын 3 майга төгәлләде. 35 гектар мәйданда уҗым басуын тырмалау үткәрелде.

**И. ОСИПОВ,**
«Канаш» колхозы» председателе.
(«Октябрь колхозчысы»).
10 май, 1945 нче ел.
№16.

### Фронтовик семьяларына ярдәм

Районыбыз колхозлары фронтовик семьялары турында зур кайгыртучанлык күрсәтәләр. Фронтовик семьялары өчен ашлык, бәрәңге, яшелчә һәм өс-баш, аяк киемнәре бирәләр, аларның квартираларын ремонтлыйлар һәм утын, керосин белән тәэмин итәләр. Менә Егоркино колхозы. Биредә фронтовик семьялары өчен колхозның гомуми фондыннан 150 пот ашлык, 30 пот бәрәңге, 6 пот чөгендер, 12 пот кабак, 100 литр сөт, 25 килограмм йон,16 пар галош, 300 пот тупас азык бирелде.

Шулай ук Кәкре Атау һәм Аксумла авылларында да фронтовик семьяларына ярдәм яхшы оештырылды. Кәкре Атау авылында 7 семьяның квартирасына яхшы сыйфатлы ремонт үткәрелде. Колхозның гомуми фондыннан 54 пот ашлык, 60 пот бәрәңге, 10 килограмм бал, 20 килограмм йон, 8 тире һәм 5 баш терлек бирелде.

**Ф. ЧЕРНОВ.**
(«Октябрь колхозчысы»).
14 декабрь, 1944 ел.

# *22 июнь—Бөек Ватан сугышы башлануга 50 ел*

**●Мәңгелек ут янында уйланулар**

## Үлгәннәрнең каберен бел...



Илебездә Бөек Ватан сугышында һәлак булган солдатлар хөрмәтенә һәйкәл, обелиск һәм бүтән истәлекле билге куелмаган торак пункт юктыр, мөгаен. Ул безнең Норлат шәһәрендә дә бар һәм һәркайсыбыз өчен изге саналган урын. Анда туганнары, якыннары өчен һәрчак яшь-яшь калган, Ватан иминлеге хакына башларын салганнар хөрмәтенә мәңгелек ут яна. Дәһшәтле Бөек Ватан сугышы башлануга 50 ел тулган бу көннәрдә мин әлеге һәйкәл янына килэм, уйланам.

Бирегә без, гадәттә, елга бер тапкыр килэбез, бронза солдат янына чын һәм ясалма чәчәкләр куябыз, һәлак булганнарны беркайчан да онытмаска дип тантаналы вәгъдәләр бирәбез. Һәм беркайчан да биредә символик рәвештә күмелгән, биредәге плитәгә исемнәре теркәлгәннәрнең берсен дә диярлек телгә алмыйбыз.

Һәйкәл янында басып торам, исемлектәге фамилияләрне укыйм. Таныш фамилияләр күп очрый: кайсы белгән, кайсы янәшәдә үскән, кайсы якын дус булганнары, 1939 елда бер эшелонда хәрби хезмәткә бергә киткәннәре дә бар.

Менә күзләрем И.А. Берстенев фамилиясенә җитеп туктала. Ваня Берстенев уку алдынгысы, спорт сөюче чибәр егет, мәктәпнең горурлыгы иде. Сөйкемле, оялчан, тыйнак Ваня иптәшләренә һәрчак игътибарлы булды. Укытучылар аның киләчәген бик өметле санаганнар иде. Кызганыч, фронттан әйләнеп кайта алмады.

Хәер, бу исемлектәге һәркем шулай. Аларны барлауны дәвам итәм. Тагын таныш фамилияләр—шук Сеня Балакирев, аз сүзле Толя Алемасов,тыйнак Гена Лесин,бертуган Евгений һәм Юрий Наумовлар. Аларның беренчесе мәктәп комсоргы, икенчесе бәхәсләшергә яратучы, гаделлек өчен көрәшүче кызу канлы егет булды. Хезмәт сөючән, һәр нәрсә белән кызыксынучан, зур күзле Павлик Казаков, укучылар һәм укытучыларның яраткан кешесе Вася Ильмухин. Ә Коля Миронов зифа каен төсле төз малайның үлгәненә әнисе Александра Даниловнаның, 90 еллыгын билгеләп узган карчык, һаман да ышанасы килми.

Мин дә Саша Елисеев,Петр Рябов, Юрий Карсунский һәм башка норлатлылар белән бергә 1939 елның салкын декабрь иртәсендә хәрби хезмәткә чакырылган идем. Ике рәт ятаклы, җылытыла торган товар вагоннарында безне көнбатышка алып киттеләр. Европа өстендә зур бәланың шәүләсе чагыла, ә төньякта фин сугышы бара иде. Ул чакта алдагы дәһшәтле елларда безнең һәркайсыбыз өлешенә нинди сынаулар төшәчәге турында уйлап карадымы икән?! Моны һәм алда телгә алган якташларымның сугышчан юлын, үлем сәгатьләрен ничек каршылауларын без беркайчан да белә алмабыз инде.

Тагын исемлеккә күз салам. Петровлар фамилиясе икәү анда, әмма минем якын дустым Петр Васильевичны, ни сәбәпледер, язмаганнар. Өлкән буыннар озын һәм төз Петровны хәтерлиләр. Яшь техниктөзүче станциядә беренче өч катлы йортны салдырды.

Сугышка киткәч ул да хәбәрсез югала. 1942 елда көнчыгышка баручы санитар поезд Норлатта туктала. Аның вагоннарының берсендә үләрлек дәрәҗәдә җәрәхәтләнгән Петров ятканлыгы турында хәбәр тарала. Легендага әйләнгән хәбәр инде бу. Әмма шуны ишетеп Петр Васильевичның әти-әнисе станциягә килгән дигән сүз йөри. Ул чакта, әлбәттә, поезд станциядән әллә кайчан киткән була инде. Ата-ана баласын, яшь хатын ирен, кечкенә кыз әтисен күрми кала. Күңелчәк, җәйге кичләрдә яшьләрнең күңелен ачтырган дустымның кая күмелгәнлеге дә билгесез. Яп-яшь килеш тол калган хатыны Валентина Аверьяновна—олы яшьтәге, авырулардан интегүче карчык—ире салган йортта яши. Мәскәүдә яшәүче кызы да инде олы яшьтә.

Бу исемлеккә эләкмәгән якташларым тагын да бар. Григорий Ларин 1941 елдагы җиңелүләрне, чигенүләрне җилкәсендә татый, әсирлек хурлыгын башыннан кичерә. Анда мин үлемнән исән кала. Әмма язмышы шулай хәл итә ки, 1945 елда туган нигезенә кайтып җиткәндә, кем әйтмешли, бусагасы төбендә җан тәслим кыла.

Уйларым сугыш корбаннарыннан ул мәхшәр эченнән исән чыкканнарга күчә. Алар, табигый ки, бу исемлеккә кермәгән, ташландык зияратта алар җирләнгән каберләр генә ел саен ишәя бара.

Бүген исән ветераннарның күбесенә дә гомер итү җиңел түгел. Болганчык замана, илнең кая таба тәгәрәвен аңлый алмау, үзләренең балалары, оныклары өчен курку йөрәккә сагыш өсти. Алар бүгенге кебек замана хакына түгел, якты киләчәк өчен кан койдылар ич.

Материаль яктан да аларның күбесе ярдәмгә мохтаҗ. Күбесенең сәламәтлеге какшаган, арада бөтенләй ялгызлары да бар, аларның хәле тагын да мөшкел. Алар һәрьяклап ярдәмгә, игътибарга лаек.

...Бүген, Ватаныбыз тарихында иң кыен чорга бәйле көннәрдә, һәйкәл янына басып уйлаганда мин якташларыбызга, егетләргә һәм кызларга мөрәҗәгать итәм. Бу мемориаль янымнан беркайчан битараф узмагыз. Бу исемлеккә теркәлгәннәрнең барысы да сезнең кебек яшь, чибәр һәм көчле булганнар, аларның да яшисе Ватан файдасына хезмәт итәсе, сөясе һәм сөеләсе, балалар үстерәсе бик килгән. Онытмагыз аларны, җылы сүз белән искә алыгыз. Үлгәннәрнең каберен бел, исәннәрнең кадерен бел дигән әйтемне исегездә нык тотыгыз! Безнең исән-иминлегебез өчен гомерләрен корбан иткән әти-бабаларыбызны истән чыгарырга хакыбыз юк безнең.

**В. ПОСЕЛЕННОВ.**
Норлат шәһәре.

## Исемнәре белән искә алыйк



Каберләр.... Каберләр... Күбәү алар. Аерым гына да, туганнар, билгеле һәм билгесез каберләр. Безнең киң илебездә һәм Бөек Ватан сугышы хакимлек иткән башка илләрдә күп ме алар. Илебез һәм Көнчыгыш Европа илләре картасына күз салыгыз, сез аннан безнең солдат тамга салмаган урынны тапмассыз:

Усманов Барый Талипович, Кизләү авылы—Сталинград өлкәсе, Рогачи шәһәре.

Минхәеров Әхмәт Гәрәевич, Октябрь районы—Төньяк Осетия, Ардан авылы..

Евлейкин Николай Алексеевич, Мамык авылы—Молдова, Тирасполь шәһәре.

Советлар Союзы Герое Синдряков Николай Кузьмич, Иске Чаллы—Киев өлкәсе.

Исхаков Салих Зиннәтович, Карасу авылы—Белоруссия СССРның Заречье авылы.

Советлар Союзы Герое Козлов Николай Андреевич, Тимерлек авылы—Ленинград шәһәре.

Фәйзетдинов Абдулла, Кычытканлы авылы—Литваның Валенгур районы.

Гарифуллин Рәхмәтҗан Андреевка авылы—Латвия.

Кашапов Мингали Әхмәтович, Фома авылы—Латвия, хутор Яунтепши.

Гаязетдинов Кәрим, Зирекле авылы—Эстония, Локутье хуторы.

Герасимов Василий Прокопьевич, Мамык авылы—Финское Каирово авылы.

Гиниятуллин Мулла Сәитович, Кычытканлы авылы—Польша, Явожно.

Миндубаев Гайфулла, Салдакай авылы—Чехословакия, Велен-Дносве шәһәре.

Бабушкин Алексей Степанович, Богдашкино авылы—Венгрия, Валяскуро.

Мөлеков Сәйфи Фәтхетдинович, Иске Әмзә—Румыния, Киркиненш авылы.

Мазаков Сергей Иванович, Иске Чаллы—Югославия, Нагатин шәһәре.

Алексеев Лев Михайлович, Единение поселогы—Австрия, Рамзау.

Вәлиев Касыйм Хәсәнгатович, Кәкре Атау авылы—Германия, Генстенбург.

Ефремов Герман Сергеевич, Мамык авылы—Карелия, Пнкарянте шәһәре.

...Әлегедәй хәтеремдә. Кыр госпиталендә (Германиядә) ятканда штаб начальнигы миннән фанерга «Красноармеец... 1921—1944» дип язарга һәм аны кабер өстенә кадап куярга кушты. Ә туганнарына: «Яраларыннан үлде, урманнан 0,5 километр ераклыкта Альтенау ягындагы юл чатына күмелде», дигән кара мөһер сугылган кәгазь китте.

Белмим, ул кабер һәм язмалы такта кисәге саклангнмы? Тик шунысы мәгълүм, 26 миллион кешебез (шуның 6300е безнең районныкы) һәлак булды. Аларның фамилияләре Норлат шәһәрендәге мәңгелек ут янындагы һәйкәлгә язылган. Һәм исемлек һәр елны яңадан-яңа фамилияләр белән тулылана.

Туганнар каберлеге бездә дә бар. Сугыш чорында Норлатның 2 нче мәктәбендә 3654 нче номерлы госпиталь урнашкан була. Врачлар ничек кенә тырышсалар да, 10 сугышчының тормышын саклап кала алмыйлар. Аларны Тарн Варн зиратына күмәләр.

1985 елның 9 маенда анда тантаналы шартларда һәйкәл ачылды. Гәүдәләре безнең туфракта күмелгән солдатларның туганнары килгәннәр иде. Менә аларның фамилияләре:

Скляр Трофим Моисеевич, Сәлимов Әюп Йосыпович, Бахарев Георгий Викторович, Леонов Николай Лаврентьевич, сержант Гончарев Василий Павлович, Лоденщиков Андрей Павлович, Моновей Иван Андреевич, Старков Василий Иванович, өлкән сержант Краснов Александр Андреевич.

Ел саен, җиңү көнендә, сугышта һәлак булучыларга куелган һәйкәл һәм обелисклар янына чәчәкләр салабыз. Әйдәгез, Бөек Ватан сугышы башлануның 50 еллыгы көне, 22 июньдә барысының да исемнәрен күңелдән кичерик, Ватаныбызның намусы һәм азатлыгы, тынычлык хакына гомерләрен биргән солдатлар истәлеге алдында баш иеп, чәчәкләр бүләк итик.

**И. САНДЛЕР.**



# Сагынып сөйләрлек итеп

**Сабантуй «Комбайн» колхозы эшчәннәре өчен икеләтә бәйрәм булды. Бу көнне аларга күптәнге дуслары—Латвиянең Бауск районы «Узвара» агрофирмасыннан кунаклар килде.**

Район колхозларының һәрберсендә сабантуй үткәрүгә төрлечә караш яши. Кайберәүләр әйтә: «Бер колхозда гына сабантуй үткәрү күңелле түгел, кеше аз, халык пассив була», диләр. «Комбайн» колхозы эшчәннәре өченче ел инде шул фикерне нык итеп кире кагарлык саф милли, матур итеп, зур әзерлек белән сабантуй үткәреп яталар. Камил сценарий буенча, борынгы сабан бәйрәменең барлык элементларын диярлек хәтердә яңартылган, халыкны тартырлык күңелле тантана гаҗәеп матур Муллалар аланында үтә. Җомга көн иртән генә килеп төшкән латыш кунаклар—Бушманис Ивар, «Узвара» агрофирмасының «Арумс» («Пахота») күптиражлы газетасы редакторы, группа җитәкчесе—баш инженер-төзүче Мадҗулис Ояр һәм тәэминат һәм реализация бүлеге начальнигы Барановскис Валдис беренче сәгатьләрдән үк үзләренә гаҗәеп дустанә, җылы мөнәсәбәт сизделәр. Сабантуйда кунакларга татар гадәте буенча ипи-тоз тапшырылды. Бәйрәм сценариена алар өчен дә, башка кунаклар өчен дә колхоз тарихы, бүгенге экономикасы, социаль хәле, ике хуҗалык арасындагы дуслык турында тулы мәгълүмат та кертелгән иде. Сүз уңаеннан сабантуйның буеннан-буена микрофон бушамады. Анда һәр уенга, һәр ярышка карата күңелле шигырь, дәртле җыр дисеңме, үзвакытында кертелгән информация, таныштырумы—һәммәсе бәйрәмдә катнашучыны кайбер хуҗалыклардагы төсле ялгыз, «сукыр» калудан коткара, мәйданны берләштереп, туплап тора иде. Бу яктан күп авылларга әмзәлеләрдән өйрәнү комачауламас иде. Хәер, бу яктан гына дип әйтү гадел булмас иде:иң мөһиме—бәйрәмне чын бәйрәм итү сәнгатенә өйрәтерлек тәҗрибәләре бар «Комбайн» колхозының. Әлеге төшенчәгә күп нәрсә керә: шул ук бөтен сценарий да, үзешчән сәнгать көчләрен кузгату да, халыкның иң борынгы уеннарын табып, катнашучыларны тарту да, аларга үзвакытында нәтиҗә ясый бару да, кыр батырларын олылау да, авыл аксакалының фатихасын алу да, көрәш үткәрү дә—һәммәсе ыгы-зыгысыз, тәртип белән халык игътибарын җәлеп итәрлек итеп оештырылды. Хәтта бәйрәмгә килгән иң өлкән һәм иң яшь кешенең күңелен күрергә дә онытмадылар. Иң олы яшьтәге Фәттах бабай Гыйләҗев бик озаклап рәхмәт әйтте, Фәридә һәм Фәрит Гыйльметдиновлар да кечкенәләре өчен җылы юрганны сөенеп алып киттеләр.



Латыш дуслар КПСС райкомының II секретаре Ә. В. Мөлеков белән.

Латыш дуслар бәйрәмне зур кызыксыну белән күзәттеләр. Ивар бәйрәмнең беренче минутыннан ук фильмга төшерде—«Арумс» газетасында мәкаләдән тыш, әле ул бу дуслык элемтәсе, милли бәйрәм турында фильм да эшләячәк. Латышлар үзләрендә шундый бәйрәм юк, диделәр. Ә шулай да озаклamый—23 июньдә шундый милли бәйрәмнәре «Лиго»ны көтеп алалар. Ул иң озын көнгә багышланган. Кичтән учаклар ягып, аның тирәсендә биюҗыр белән үтә икән ул бәйрәм. Бу көнне имән яфракларыннан такыялар үрәләр, махсус әзерләнгән сельд белән сыра эчәләр, озын көнне сәламлыйлар. Безнең бәйрәмнең күңелле уеннары алар күңеленә бик хуш килде. Татарларның атка мөнәсәбәтләренә сокландылар. Әмзәдә, һәр елдагы шикелле, быел да ат чабышлары әйбәт узды. Призлы урынны алган атларга (җайдаклары В. Курочкин, Т. Асылханов, С. Курочкин) зур бүләкләр тапшырылуын табигый дип санасалар да, ахыр килгән атка әбиләр йөгерешүен аңламый аптырадылар. Нәзер, вәгъдә безнең халыкка хас нәрсә булуын төшенделәр тагын.



Кунакларны ипи-тоз белән каршы алдылар.

Татарча көрәш башлангач, Валлис Барановскисның күзләре үк җанланып китте. Тыйнак кына дәшми утырган кунакның «серен» иптәшләре ачты—ул замасында Латвия беренчелегендә классик көрәш буенча 5 тапкыр җиңгән кеше икән. Икенче ел төп батыр калучы сөт ташу машинасы шоферы Дамир Фәтхетдиновка келәм, тәкәдән тыш Латыш дусларының милли сөлгесен алу да насыйп булды. Аны нәкъ Валдис тапшырды, батырны күтәреп (чөя генә күрмәсен диештек!) тә күрсәтте. Колхоз батырларының икенчесе—Рафик Хәлилов, өченчесе Рәсим Мусин булды. Кайткан кунаклар арасында 1 нче урынны Николай Поляков, икенчесен Николай Скворцов яулады.

Сабантуйның бик бай лоторея уеннары да кызыклы узды.

Иварс әллә нигә кызыксынды: бу авыл сабан туена гына хас үзенчәлек нәрсәдә, диде. Милли горурлык безне бераз «сасрак кыланырга» мәҗбүр итте: бу—район хуҗалыкларында үткән иң әйбәт сабантуй, кайбер җирләрдә аны сәгать ярымда ике чүлмәк ваттырып үткәреп ташлыйлар димәдек. Ике көннән соң үз авызларыннан барыбер шул бәяне ишеттек.

—Бу бәйләнеш сезгә нәрсә бирә?

Сорауга җавап күпкырлы булды. Иң элек аның моннан күп еллар элек тә бартер нигезендә башланып китүен искә төшерделәр. Люцерна орлыгы озын гомерле, бәрәкәтле шытымнар бирде: ике як өчен дә файдалы хезмәттәшлек хәзер дә дәвам итә: безнекеләр аннан нәселле таналар, яшелчәләр, консервланган яшелчә, җиләк-җимеш, шикәр комы алсалар, анда борчак, сумала һәм башкалар озатыла. Соңгы олаулар Латвиядән әле июнь башында гына кайттылар. Августта яңа визит көтелә. Инде икенче ягы—әлбәттә, дуслык, аралашу шатлыгы, гореф-гадәтләрне күрү, өйрәнү мөмкинлеге. Бу яктан һәр ике халыкның уртаклашыр сүзләре шулай ук аз түгел. Латыш дусларыбыз бүген татар халкының мөстәкыйльлек, азатлык өчен көрәшен аңлап хуплыйлар, уңышлар телиләр.

Бәйрәмнәр узды, Әмзә халкы кунакларны зурлап, хөрмәтләп юлга озатты. Ә быелгы сабантуй хатирәләрен, һәр якты истәлек кебек, халык озак вакытлар сагынып сөйләр әле, хуҗалык җитәкчелегенең эшне генә түгел, ялны оештыруда да хуплап телгә алыр. Һәм бу һичшиксез эшкә мөнәсәбәттә дә чагылмый калмас! Кем әйтмешли, безнең халык үзен зурлаганга җанын ярып бирергә әзер.

**С. ХӘЙРУЛЛИНА.**

**ЯҢАЛЫКЛАР**

## Халык рәхмәте

**Безнең кустка кергән Андреевка, Богдашкино, Киекле, Кизләү, Чаллы авыллары халкына шатлык килде. Билгеле булганча, безнең төбәктә яшәүчеләргә Иске Чаллы участок шифаханәсе хезмәт күрсәтә. Авыллар халкына, бигрәк тә олы яшьтәге, чирле кешеләргә шифаханәгә бару зур кыенлыклар тудыра иде. Күптән түгел без бу мәшәкатьләрдән арындык.**

**Район үзәк шифаханәсенең баш врачы З. А. Шабаев, Иске Чаллы участок шифаханәсе баш врачы А.Л. Клементьев колхоз җитәкчеләре белән сөйләшеп киңәшкәннән соң, авыруларны йөртергә махсус машина җибәрергә булалар. Хәзер үзәк шифаханә машинасын дәвалау-профилактик амбулатория авырулар ташуга җиһазлады. Машина һәр көн саен тирә-юньдәге авылларның медицина пунктларында була, аннан авыруларны утыртып участок шифаханәсенә алып килә һәм кире авылларга илтә.**

**Әнә шулай итеп, җитәкчеләрнең кайгыртучанлыгы аркасында халыкка бу яктан зур уңайлыклар туды һәм моның өчен халык рәхмәте олы аларга.**

**Г. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН.**

## Яңа газета

РОССИЯ крестьяннары өчен яңа газета чыга башлады. Ул «Крестьянская Россия» дип атала. Яңа басманың беренче санында Б. Ельцин һәм И. Силаевның котлаулары басылган. Бу газета РСФСРда фермерлык, авылда базар мөнәсәбәтләре һәм башка көнүзәк темаларны яктыртуга исәп тота.

# Уналты оныклары бар

Андреевка авылына килеп кергәч тә, кирпечтән салынган таш өй, аннары агач өй күзгә ташлана. Менә шул йортта Будяшкиннар гаиләсе яши дә.

Ольга Егоровна белән Иван Архипович инде пенсия яшендәге кешеләр. Елдагыча, быел да түземсезләнеп оныкларының җәйге ялга җыелып бетүләрен көтәләр. Онықлары дигәннән, аз түгел, уналтау гына.

—Узган җәйдә 28 кеше җыелдык, йокларга урынҗир җитмәде,—дип көлеп искә төшерә Ольга Егоровна.— Быел да шулай булыр инде.

Һәм ул бармакларын бөгә-бөгә, авыз эченнән генә балаларның исемнәрен барлый башлый: Валерий, Анна, Альбина, Галина, Людмила, Елена, Николай, Нина, Вера, Надежда...

Ун баланы тәрбияләп үстерүе алар өчен, әлбәттә, җиңел булмаган. Төрлесе төрле характерлы, һәрберсенә аерым мөнәсәбәт кирәк. Тик берсе дә ким-хур булмады, үзләренең сәләтләренә карап белем алдылар. Хәзер әнә Верасы «Сөлчә» совхозында аптека, ә Нинасы Андреевкада китапханә мөдирләре, Анна Норлат шәһәрендәге район үзәк больницасының балалар тудыру бүлегендә шәфкать туташы булып эшли. Төпчек кызлары Надежда укытучы профессиясен үз итте. Казан Дәүләт педагогия институтының II нче курсында укый. Әле яңа гына сессиягә китте.

Бу хәтле балага нәрсә ашаталар соң? Кибеттән бит бүгенге көндә теләгән әйберәңне барып алып булмый. Будяшкиннар бу яктан да тыныч:

—Сыер исән булсын,—диләр алар.—Май белән сөт өстәлдән төшмәс. Аннан ит, бәрәңге, икмәк, 7 баш умартабыз бар...

Умарта дигәннән, Иван Архипович 18 ел колхоз умарталыгында эшләгән кеше.

Үзе ул көннәр турында болай ди:

—1983 нче елга хәтле эшләдем. Көн саен 7 километр ераклыктагы «Яңа юл» колхозындагы урман эченә урнашкан бу умарталыкка ат белән йөрдек. Улым Николай да миңа булышты. 117 умартаның һәрберсеннән 10ар килограмм бал ала идек. Миннән соң, Владимир Ильич Воспенников эшкә килде, тик бер елдан соң колхоз умарталыгы бөтенләе белән таркалып бетте.

Иван Архипович үзеннән үзе генә умартачы булып китмәгән. 1955 нче елларда элекке Тельман районында ул махсус белем алган. Нинди генә эш кушсалар да, зур җаваплылык хисе тоеп, намус белән башкарган. Баштагы чорда авыл Советы секретаре һәм председателе дә булган. Кыскасы, хуҗалыкны һәм аның кешеләрен үзенең биш бармагы кебек яхшы белә.

Бөек Ватан сугышы үсмер егет Иван Архиповичны да читләтеп үтми. 1943 елда сугышка китә, элемтәче булып хезмәт итә. Шул елның 19 июнендә беренче мәртәбә Прохоровка авылы янында, икенче мәртәбә 1944 елның 27 декабрь аенда Чехословакиядә каты яралана. Озак вакыт госпитальдә ятып чыга. Украина, Бессарабия, Румыния, Венгрия, Чехословакияне азат итүдә катнашкан бу кешегә авылдашларының хөрмәте чиксез зур.

Ольга Егоровнаны исә авылда үткәнендә унган колхозчы, Герой-ана буларак яхшы беләләр.

Аның тагын бер ягы бар—татар телендә өздереп сөйләшә.

—Балалар исән-сау булсыннар, дөньялар гына тыныч торсын,—диләр картлар икесе берсүздән.—Без яшисен яшәдек инде. Ә хәзер балаларыбызга озын гомер телибез...

**Г. РӘХИМОВА.**

Газиз КАШАФ ҮЗИЛЕ

## Июнь таңы

50 ел элек Бөек Ватан сугышы башланды.

Һәр ел саен килә бу таң Җиргә,
Сандугачлы, җылы, җәйге таң.
Тик колакта барыбер таныш тавыш,
Тетрәндерә җанны Левитан.

Ишетелми шартлау-гөрселдәүләр,
Кыйпылчыклар очмый сызгырып.
Ул чакта да шундый гүзәл булып
Атты микән таңнар сызылып?

Уйлап ятам кара тиргә батып,
Әйтерсең лә үзем яуда мин?
...Әнкәй елый соргылт кәгазь тотып,
Ник берәү дә аны аңламый...

Ә кайдадыр тагын сугыш бара,
Яралылар канга манчыла.
Мин сискәнеп учларыма карыйм,
Учларыма тама тамчылар.

Ишетәм сыман ярдәм сорауларын,
Ыңгырашуларны ишетәм.
Әткәйләрнең төсе итеп, ахры,
Солдат туганымны иш итәм.

Әнә тагын чыжлап күккә ашты,
Ракетаның алсу шәүләсе.
Җаным әрни экраннарда күрсәм
Күмелмәгән солдат гәүдәсен.

Күтәрәсем килә «Тревога» дип,
Җир шарының барлык илләрен.
Терелтәсем килә сугышларда
Ятып калган барлык ирләрне.

Прожекторлар янсын күкне айкап,
Туплар атсын—төсләр балкышы.
Бөтен галәм киңлегенә китсен,
Тынычлыкның мәгърүр алкышы.

Һәр ел саен килә бу таң Җиргә,
Сандугачлы, җылы, җәйге таң,
Тик колакта барыбер таныш тавыш,
Тетрәндерә җанны Левитан.

## Очрашу

Урман чите. Иртә. Җәйге кояш,
Һәм танклар уза берәм-берәм.
Юк, сугышка түгел, өйрәнүгә,
Полигонга таба, төгәл беләм.
Тирә-юньдә шау-шу,
Күңелдә шом...
Шлагбаум алда—киртә тора.
Әллә чынлап, әллә ялгыш кына,
Танкларның берсе тубын бора.
Шул чак тупның кара күзен күрәм,
Менә-менә ут бөркелер сыман.
Уйлыйм башлыйм ис-акылым китеп,
Ул күзгә бит күпме үлем сыйган.
Мин шинельне элеп куйдым күптән,
Кирза итекләрне күптән салдым.
Мин казыган тирән окоплар да,
Амур ягы тауларында калды.
Тик хәтердән никтер чыкмый бер хәл,
Соңгы өйрәнүгә апбардылар.
Чыныксыннар диеп шунда безне,
Дулкын-дулкын танк таптадылар.
Үзем көләм: бу бит уен гына,
Үлем дигән нәрсә ерак моннан.
Тик барыбер дәһшәт-гөрелтесе,
Хәзергәчә китми колагымнан.
Шул чакта мин, әй, хыялый бәндә,
Чын сугышны күргән кебек булдым.
Үләннәрдән тамган чык тамчысы
Җирдә яткан каска эченә тулды.
Шунда гына мин үземне үзем
Ил сакчысы—солдат итеп тойдым.
«Куыш»тагы гранатаны алып
Чикәсенә бармагымны куйдым...
Шартлау тавышы гөрселдәде кинәт,
Көлтә хәтле ут бөркелеп алды.
Әйтерсең лә буш бер нәрсә түгел,
Туган өем шунда шартлап янды.
Урман чите. Иртә. Җәйге кояш,
Һәм танклар уза берәм-берәм.
Юк, сугышка түгел, өйрәнүгә,
Полигонга таба, төгәл беләм...

Чаллы шәһәре.

## Авылым ветераннарына сүз

Сугыш һәм җиңү. Ветераннар һәм сугыш. Бу төшенчәләр бер-берсеннән аерылгысыз. Сугыш хәсрәте һәм җиңү шатлыгы капмакаршы хисләр уятса да, аларны бер-берсеннән башка күзаллап булмый. Бүген дә шулай: илебез, халкыбыз кичергәнне онытмыйча, бүгенге тыныч көн өчен шатлана белик. Җиңү көненә сугыш ачысы аша, кайгылы һөҗүм таңына җиңү сөенече аша карасак кына яшәүнең кадерен тулысынча аңларбыз кебек. Шуңа күрә чиксез югалтуларның, сүрелмәс кайгы-хәсрәтләрнең башы булган 22 июнь көнендә 9 май тантанасында әйтелгән сүзләрне хәтердә яңарту синең өчен дә гаҗәп булмас, кадерле укучы. Хәбәрчебез Ф. МӨХӘММӘТОВАның бу шигъри репортажында быелгы Җиңү бәйрәменең Югары Норлат авылында ничек узганы тасвирланган.

Җиңү көне бүген—Бөек Җиңү!
Ветераннар итә тантана.
Дөнья тып-тын, җилсез җылы һава,
Табигать тә гүя шатлана.
Киң урамны шау-гөр килеп әнә,
Ветераннар килә тутырып.
Бәйрәм хөрмәтенә оештырган
Мәҗлестән чыккач утырып.
Кәефләнеп бераз алганнар да—
Гөнаһ түгел Җиңү көнендә.
Фашист дигән явыз илбасарны
Дөмбәсләгән алар өнендә.
Каршы чыккан Юныс, кулларында—
Көмеш кыңгыраулы тальяндыр.
Ветераннар сафын сирәгәйткән
Әткәсен ул искә алгандыр.
Ә Нургали абзый күкрәгеннән
Ургылыпмы бер җыр агыла.
Тән ярасы салган авыр газап
Йөрәгенә гүя кагыла.
Унҗидедә сугышларга кереп,
Унсигездә калып бер куллы,
Ник соң әле җырламаска тиеш,
Җырласын ул, хакы бик олы.
Генералның хәтта үзен йөрткән
Солтан абый гашыйк җыр-моңга.
Күпме юллар үтеп гади солдат,
Барып җиткән ерак Берлинга.
Артиллерист Галиулла агай
Хискә чумган, нидер уйлана.
Юкка гына мини төшләрендә,
«Огонь!» диеп куркып уяна.
Ә тальянның теле кай арада
Бию көен инде сиптерә.
Мәүлет абзый, Шәяхмәт агайлар
Яшьләр кебек—ничек типтерә!
Егетләр дә көнләшерлек итеп,
Чүгеп бии Исламнур агай.
Ерак Көнчыгышта бу лачынны
Чүктермәгән хәтта Самурай.
Бер читтәрәк Галимҗан бабай да,
Ильяс бабай һәм Таһир ага.
Җуелмаслык сугыш хатирәсе,
45 кә кабат юл ала.
Ветераннар килә урам буйлап,
Зурладылар бүген үзләрен.
...Яулык чите белән моңсу гына,
Тол әбиләр сөртә күзләрен.
Әйтер сүзем—соңга калмыйк берүк,
Исәннәрнең белик кадерен.
Шәһитләрнең, чәчәкләргә күмеп,
Пакълап тотыйк изге каберен.
Салкын мәрмәрләрдән һәйкәл түгел,
Зур хөрмәткә лаек ветеран.
Шәфкатьлелек җылысына төреп,
Бүләк итик тирән ихтирам!

9. 05. 1991 ел.

## Котлыйбыз!

Киекле авылында яшәүче сөекле әниебез Рәтифә Хәйрулла кызына 50, әтиебез Нәфыйк Нуретдин улы Насретдиновка 54 яшь, ә бергә тормыш корuларына 32 ел була. Аларны туган көннәре белән котлап, матур гомер кичерүләрен телибез.

БАЛАЛАРЫ.

## КОРБАН БӘЙРӘМЕ

Корбан китерү бәйрәме—ислам динендәге ике олы бәйрәмнең берсе (икенчесе—гаид әл-фитыр—Ураза бәйрәме). Корбан бәйрәме Ураза бәйрәменнән соң 70 көн үткәч уздырыла. Исламда корбан чалу Авраам (Ибраһим) пәйгамбәр турындагы Тәүрат легендасы нигезендә кертелгән. Имештер, Кәгъбә храмын төзегән Ибраһим пәйгамбәр Җәбраил фәрештәдән «кара таш»ны алгач, үзенең Аллага бирелгәнлеген күрсәтү өчен, улы Исмәгыйльне корбан итмәкче була. Ләкин шәфкатьле Алла, Ибраһимга фәрештә аша бәрән җибәреп, аның улын коткара. Хак диндәге һәрбер мөселман шушы вакыйга истәлегенә Аллага багышлап корбан чалырга, ягъни сарык, сыер яки дөя суярга тиеш. Моның сәбәбе шунда: әлеге бәйрәм көнне Аллага багышлап корбан чалмаган кеше теге дөньяда оҗмахка эләгә алмый, чөнки тәмуг аркылы салынган «кылдан нечкә, кылычтан үткен» сират күперен мөселман корбанга чалынган терлеккә атланып кына кичә ала, имеш.

Безнең илдә, билгеле сәбәпләр аркасында, мөселманнарның күбесе эре терлек корбаны урынына мәчеткә акчалата гына хәер бирә яки кош-корт, вак мал чала. Үтә диндар мөселманнар Корбан бәйрәме алдыннан ун көн ураза тоталар.

Корбан бәйрәме иртә таңнан башлана. Таң ату белән мөселманнар мәчеткә иртәнге намазга баралар. Әмма аңа кадәр тәһарәт алып, чиста яңа кием кияләр, тәннәренә ислемайлар сөртәләр. Намаз алдыннан ашарга рөхсәт ителми. Иртәнге намаздан соң, өйләренә таралалар. Аннары, теләкләренә карап, урамда я ишек алларында төркем-төркем җыелып, тәкбир әйтәләр. Аның соңында яңадан мәчеткә яки махсус ачык мәйданга (кагыйдә буларак), ул шәһәр читендә була) барып, мулла я имам-хатиб хөтбә укый, ягъни вәгазь сөйли.

Хөтбә гадәттә Аллаһы Тәгаләне һәм аның пәйгамбәрләрен мактау белән башлана. Аннан соң хаҗның барлыкка килүе һәм корбан чалу йоласының мәгънәсе аңлатыла. Тәҗрибәле имам-хатиб вәгазен рифмалы проза формасында әйтеп бирә.

Вәгазь беткәч, мөселманнар, зиратка барып, үлгәннәргә дога кылалар. Шунда ук җирле «изгеләр»нең төрбәләренә дә табыналар. Аннан соң, өйләренә кайтып, корбан чалу йоласын башлыйлар.

Корбанга дип сайланган изге малга мулла яки мәзин Ибраһим пәйгамбәрнең корбан китерүе турында әйтелгән дога укый. Бу вакытта мал хуҗасы яки махсус ялланган кеше корбанны чала башлый. Корбан малына теләсә кайсы мөселман «Бисмиллаһи, Аллаһы әкбәр!» ягъни «Аллаһы тәгалә өчен, Аллаһ бөек!» дигән кыска гына сүзләр белән дога кыла. Бәрән яки сарыкны чалыр алдыннан башын Мәккәгә каратып егалар. Сарыкның җыелган канын һәм бавырын яктылыктан яшерер өчен, кара чүпрәккә төриләр. Алар зур әһәмияткә ия. Сарыкның күзләреннән амулет (нәзәри корбаны) ясыйлар. Корбанга чалынасы мал бер яшьтән дә яшь булмаска, сәламәт һәм кимчелекләрсез булырга тиеш. Сарык яки кәҗә бер кеше исеменнән генә, ә сыер, үгез, дөя исә җиде кешедән корбанга китерелә. Гадәттә сарык, сыер, кәҗә һәм үгезнең ике яшьлекләрен, дөянең биш яшьлеген чалалар. Корбанны сау-сәламәт яшәүчеләр өчен генә түгел, мәрхүм-мәрхүмәләр исеменә атап та чалырга мөмкин.

Корбан малының тиресен, гадәттә җирле мәчеткә тапшыралар. Итен пешереп, бүргәләшеп ашыйлар. Анда кайчакта мулла яки мәзин дә була. Корбан бәйрәмендә һәр мөселман кешесе гөшт яки кебаб дигән итле ризык ашарга тиеш. Бу көннәрдә төрле ил мөселманнары үзләренең йола ашларын әзерлиләр. Бу бәйрәм—шатлыклы вакыйга, шуңа күрә бәйрәм ашы да төрле һәм тәмле булырга тиеш. Безнең илдәге мөселманнар пылау, манты, шашлык, лагман, пилмән, бишбармак һәм башка итле ашлар, төрле-төрле салатлар әзерлиләр. Корбан бәйрәме алдыннан көлчәләр дә пешерелә. Балалар һәм хатыннар күптөрле татлы ризыклар белән дә тукланалар.

Корбан бәйрәмендә һәм аннан соңгы өч-дүрт көн эчендә туганнары һәм дус-ишләре белән кунакка йөрешәләр, кыйммәтле булмаган бүләкләр бирешәләр.

МӨХӘРРИР Ә. У. АБДУЛЛИН.

Учредительләр халык депутатларының Октябрь район Советы, КПССның партия оешмасы.

Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.
ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге— 2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.

Газетаны Нурзия ФӘСХЕТДИНОВА җыйды. АСИЯ МОРАТХАНОВА верстка ясады. Фирдания ХУҖИӘХМӘТОВА басты. Корректор—Рәзинә ШӘЙХУЛЛИНА.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә. Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе. Күләме—1 басма табак. Заказ 74, Тираж 3415.